АССОЦИАЦИЯ
«СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНЫХ
ОБРАЗОВАНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ
СОВЕТЫ»
АССОЦИАЦИЯСЕ

**РЕШЕНИЕ ПРЕЗИДИУМА** **ПРЕЗИДИУМ КАРАРЫ**

от 12.03.2020 № ПР-163-1

г. Казань

**Җирлекләрнең территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелеше зоналашуы документларын әзерләү һәм Татарстан Республикасы торак пунктлары чикләре турында күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрына кертү буенча эшләрнең барышы турында**

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры Ф. Ә. Әһлиуллин мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе Президиумы (алга таба – Совет) **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры Ф. Ә. Әһлиуллинның мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

- территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру документларын әзерләү һәм әлеге органнар тарафыннан билгеләнгән мәгълүмат бирү вакыт чикләрен үтәү буенча комплекслы чаралар үткәргәндә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, «Татарстан Республикасы пространство белешмәләре фонды» ДБУ һәм Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән уртак эшне тәэмин итәргә;

- территориаль планлаштыру документларын әзерләү буенча чараларны өстәмә финанслауга инвесторларны җәлеп итү буенча эш алып барырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Советның башкарма сәркатибе А.Г. Барышевка йөкләнә.

**Рәис** **Ә.С.Гобәйдуллин**